Республика Татарстан
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул.Ахмадиева, д.26, п.Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-99, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы, 423368
Телефон: (85559) 31-0-99, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОКПО 93068410, ОГРН 1061687003069 ИНН/КПП 1636005574/163601001


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
20.12.2021 ел №41

«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә фейерверклар һәм салютлар җибәрү өчен урын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы РФ Хөкүмәте карары белән, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Яңа ел бәйрәм чаралары вакытында гражданнарның һәм объектларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Җәлил шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге территориясендә фейерверклар һәм салютлар җибәрү урыны итеп Сарман районы, ш.т. п. Җәлил, Әхмәдиев ур., 30а адресы буенча урнашкан «Мәйдан» автостоянка участогын билгеләргә.
2. Фейерверклар урнаштырганда мәйданчыкны саклау һәм гражданнарның иминлеге фейерверк уздыручы оешмага яки затка йөкләнә. Тамашачылар җил искән якта булырга тиешләр.
3. Фейерверк үткәрү урыныннан алып биналарга һәм тамашачыларга кадәрге ераклык кулланыла торган пиротехник эшләнмәләр инструкциясе таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә, шулай ук мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Башкарма комитет җитәкчесе И.Ф. Галлямов